

# ГАИЛӘ БИТЕ

## Ана сагышы

Юллар, юллар, аһ,
нинди озын,
Юл чатында ана көнозын
Көтеп торды соңгы
өмет белән,
Бердәнбер кызын.

Менә иртә
Иртә юлларга илтә
Юл өстеннән күтәрелә
күе томан

—Кайтыр кызың, ана—
диеп
Юл анага дәшә сыман.
Янә иртә. Көтә ана
Кызын капка төбендә
Күтәрелә морҗадан
күе төтен
Ана өзде соңгы өметен.

**Гөлназ ГАЛИЕВА,**
Кәкре Атау тугызьеллык мәктәбенең 9 класс укучысы.

**М. Усманова**

## Зәңгәр кыңгыраулар

Җәйнең матур иртәсендә
Елан тау итәгендә,
Йөрегән идек сокланып
Кыңгырау чәчәгенә...
Кыңгырау чәчәге төсле
Зәңгәр иде күзләрең,
Зәңгәр томаннар каплады
Без йөрегән эзләрне...
Зәңгәр томаннарда калып

Эзлимен эзләреңне...
Төшләремә генә кереп
Өзәсең үзәгемне.
Җәйләр саен киләм
елан тауга
Юксынудан үзәк өзелә.
Кыңгыраулар гына
озатып килә
Чык-яшьләрен коеп эземә.

**Ф. Мөхәммәтова**

## БЕР НАЗ

Кар-бозларны эретерлек
Карашыңда никадәр наз!
Шул назларда эремәскә
Сабырлыгым җитсә бераз?!

Сихри көчле уй-хисләрдән
Горур гына кичәргә ваз
Каршы килмә, йөрәккәем,
Иңрәп кенә бирче аваз!

Чын бәхетне тояр өчен
Кирәк икән, ах, бигрәк аз!
Җаннарымны эретерлек
Күзләреңнән сирпелгән наз!!!
Сөюләрнең ташкын хисен
Татыр өчен бик аз, бик аз
Гомеремнең көзләрендә
Балкып килде бәхетле яз.
...Соңлап килде бәхетле яз...

# КӨТЕП АЛГАН ТУЙ

Авылларда көннән-көн буйдак егетләрнең артуы авыл халкында, хуҗалык җитәкчеләрендә зур борчу тудыра. Нидән шулай килеп чыга соң? Моңа төшенүе кыен түгел: егетләрнең шәһәргә китеп бәхет эзләп йөрисе килми, туган авылларында берегеп калалар. Ә кызлар киресенчә, җан теләгән эш булмагач, авылдан чыгып китү ягын карыйлар. Боларны белеп, аңлап торсак та һичнинди хәл кыла алганыбыз юк әле: буйдаклар саны арта бара. Авылда каласы яңа өйләнешүчеләр безнең өчен олы шатлыкка әйләнә. Күптән түгел нәкъ шундый куанычлы көннәрнең берсе булды.

Радикның армия хезмәтеннән кайтуына өченче ел китте. Кайткан көнендә үк авылга, колхоз эшенә җаны-тәне белән бирелде. Моны күреп ата-анасы белән бергә авыл халкы да канәгатьлек хисе белән тынычланып калдылар: болай булгач шикләнергә урын юк, Радик авылны ярата, китмәячәк диделәр. Әмма киләчәге генә күңелгә бераз борчу сала иде. Яшь, чибәр, уңган, гармунчы-җырчы, авылдашлары арасында абруе зур, колхоз җитәкчеләре тарафыннан да макталып кына торучы егет авылда буйдак булып калырга теләмәс, карап торып хатынсыз калмас бит инде. Халык шулай уйлый торды, ә Радик ашыкмады. Аңа күз атучы кызлар да бар икән дип ишетелгәләде. Шулай бер заман халык арасында Радик үзенә кыз тапкан икән дигән хәбәр таралды. Әлбәттә тапкан, дип халык арасында гына сөйләнә, дөресрәге табышканнар булып чыкты. Картлар язмыш дип тикмәгә генә әйтмиләрдер: Азнакай кызы Гөлзада Зиреклегә укытучы булып нәкъ шул язмыш кушуы буенча гына килгәндер дә. Авылның бер уңган хатыны Миннегөл апаларга фатирга кергән кыз турында хәбәр җил тизлеге белән таралды. Йорт хуҗасы кызның уңганлыгын сөйләп бетерә алмый, мәктәп коллективы якты йөз белән каршы алды, тиз арада балалар да үз итте. Билгеле, Радикның колагына болар да керми калмагандыр. Аларның вәгъдәләшүен ишеткәч, хупламаган кеше калмады, бер-берсе өчен яратылган парга ата-аналар да хәер-фатихаларын бирделәр. Көтелгән туйны гадәти генә түгел, колхоз ярдәмендә авыл белән бергә үткәрергә карар кылынды.

Тантаналы рәвештә язылышу көнне авыл культура йортына халык күп җыелган иде. Авылның йоласы шундый инде, килен төшкәндә бөтен халык урамга чыга. Бу юлы да шулай булды: Азнакай ягыннан төшүче киленне зиреклеләр җыйнаулашып каршы алдылар. Авыл Советы секретаре Евгения Степановна Крылова язылышу тантанасын игълан иткәч клуб эче тынып калды. Әйтерсең лә әкрен генә:

Тынга калды урман
буйлары да.
Чишмәләр дә акмый
тыңлады...

дигән җыр күңелләрдән агылып чыга иде бу мизгелдә.

Никахлашу тантанасы шуның белән тәмам булды. Яшьләр мәхәббәтләрен тагын да ныгыткандай, балдаклар бирештеләр, бер-берсен тәбрикләделәр. Шунда ук якын туганнары, авыл халкы котлады. Колхоз идарәсе исеменнән истәлекле бүләк тапшырылды.

Туй мәҗлесе гөрләп төп йортта дәвам итте. Биредә кызның ата-анасы белән танышу булды. Алар икесе дә гомер буе колхозда хезмәт куючылар икән, әнисе шул дәвер эчендә күп санлы мактаулар алуга ирешкән, Ленин ордены белән бүләкләнгән. Болар барысы да кызларына күчкәндер, күрәсең. Шат йөзле, җор телле булулары тагы да куандырды. Туй буена шундый уен-көлке, шаяру белән барды. Иксез-чиксез теләкләр әйтелде. Ә теләкләр бер иде: авылның киләчәк гаиләсе бәхетле булсын, имин, саулык алып килсен!

**И. ШӘЙХИЕВ.**

Никахлашу тантанасы Зирекле авылы.



«Суда,
суда,
суда
йөзә
аласыңмы...
Фотоэтюд.

# Мин Камыш бухтасыннан аваз салам

Бүгенге көндә төп темаларның берсе —эротика, секс. Ул күп кенә малайларны һәм кызларны үзенә тартты.

**Барысы белән дә мәктәптәге босслар җитәкчелек итә, алар укымыйлар, ә мәктәптә вакыт уздыралар. Класстагы босс—патша һәм алла, ул кушканча эшләмичә генә карагыз әле.**

Берсендә мин аны тыңламадым, шуннан соң яңа мыек тибә башлаган 14—15 яшьлек үсмерләр мине подвалга сөйрәп кереп көчләделәр. Ничек көчләүләре турында хәтта язасы да килми. Берсе бер кулны, икенчесе икенчесен, өченчесе башны тотып тора, ә дүртенчесе көчли. Мин акырдым, кычкырдым, еладым, ялвардым, әмма юкка гына, аннары янадылар: әйтәсең икән—яшәмәячәксең. Шулай йөрим—дәшмим, барысыннан да куркам.

Подвалда мин башка кызлар белән дә булдым. Анда эчтек, шәрә килеш биедек, сексның төрләрен өйрәндек. Бирегә ирекле рәвештә генә түгел, ә мәҗбүри алып килгән кызлар да бар иде. Соңыннан ике кыз чак-чак кына үзләренә кул салмыйча калдылар, ярый әле вакытында килеп өлгердек һәм коткардык.

Барысы да ничек башланды соң?

Ул чагында миңа 14 яшь иде, хәзер—16 ,әмма мин бөтен яктан таушалып беткән, ничек телиләр һәм кайда телиләр, шулай җәфалыйлар. Күптән түгел мин бер босска каршылык күрсәттем, ул һәм башка босслар мине көчләделәр һәм төне буенча мыскыл иттеләр. Аннары кулларымны бау белән бәйләделәр дә үзләре китеп бардылар. Шул килеш җиде сәгать утырдым, яңадан килгәч бауны чиштеләр һәм әйттеләр: Берәүгә булса да сөйлисең икән—үтерәбез. Ләкин мин барыбер милиция бүлегенә киттем. Инде барып җитәм дигәндә каршыма чыктылар. Тирә-юньдә кешеләр иде. Алар миңа күптәнге яхшы танышлары кебек эндәштеләр, елмайдылар, аннары почмакка алып керделәр, пычакны бугазга терәделәр: «Дөньяга чыгарасың икән—без утырырбыз, ә син кабердә черячәксең»,—диделәр.

**Хәзер мин шүрлим, дәшмим, мәктәпкә барырга куркам, ләкин барам. Ул адәм актыкларына карарга җирәнәм. Нәрсә эшләргә миңа, белмим.**

Ата-аналарым белән яхшы тормышта яшим, тик алар минем һәм башкалар белән нәрсә булуы турында берни дә белмиләр. Класс боссы хәтта подвалга кемнең кем белән барырга тиешлеге турында график төзеде, малайларга исә шундый-шундый көнне импорт презервативы алып килергә куша, безнең кызлар очраклы рәвештә авырга узмасыннар өчен.

Босс секс төрләрен яхшы белә, үзе дә еш кына сексларда катнаша, әле бер партнершада, әле икенчесендә барысын да өйрәтә. Соңгы вакытларда андый партнершалар 12 булды.

Болар барысы да нәрсәдән башланды?

Күпчелек малайлар һәм кызлар фикере: видеофильмнар, нәфис фильмнардан. Анда яхшыны күрсәтмиләр, мин һәм башка бик күпләр бу әшәкелекне карарга теләмиләр —бөтенесе—порнография. Босслар мәҗбүр итә. Босс әйтте: бүген кем видеога бармый, аңа начар булачак. Һәм барабыз, порнографияне карыйбыз.

**Безгә, 14, 15—16 яшьлекләргә шундый видеофильмнар карарга рөхсәт итүчеләрне каһәр суксын.**

Тормышны күрмәдек бит әле, ә сексны башыннан ахырына хәтле беләбез. Күп кенә кызлар бу яшьтә шундый тәҗрибә тупладылар ки, безнең ата-аналарыбыз да аны белми, ә алар бит кеше тормышының яртысыннан артыграгын яшәүчеләр. Беләм, үсеп җиткәч һәммәбезнең үз гаиләсен булдырасы килер. Ә мине, сөйрәлчекне кем алыр? Кемгә кирәк без бу килеш?

**Безгә ләгънәт төшкән боссларны (малайларны) фаш итүдә ярдәм итегез. Аларны шул килеш калдырсаң, бу адәм актыклары үсеп җиткәч моннан да зуррак этлекләр эшләргә мөмкиннәр.**

Бер ярминкәдә өч литрлы банкадан вино эчтек, аны исә сез саттыгыз бит әтиләр һәм әниләр. Сез безне кызганмадыгыз. Аннан соң барысы да әйләнде: әтрәк-әләмнәрнең җирәнгеч йөзләрен күрдем, алар миңа сикерәләр һәм кычкыралар: «Мин—Арлекино!». Кызганыч, сез, әтиләр һәм әниләр үзегезнең өнегездә утырасыз, телевизорга текәләсез яки китап укыйсыз, тирә-юньдә балаларыгыз ни кыланганны күрмисез.

**Өлкән дуслар, күңел кайтаргыч барлык фильмнарны алыгыз, видеоны тыегыз. Бу фильмнар безне яхшылыкка өйрәтми, шуңарга карап бөтен яшьләр шундый да:**

«Кечкенә Вера», «Арлекино», «Район җирлегендәге ЧП» кебек фильмнарны карарга барганда, мин түбән класста гына идем. Бу фильмнар өлкәннәр өчен, ә безне сексны карарга планны тутыру өчен кертәләр, соңыннан исә подвалларда аны «Арлекино кебек яшәячәкбез», «Хәзерге шартларда секс дөньясында яшәү», «Секс—безнең икмәк, безнең тормыш», «Без секстан туган, ә кәбестәдән табылмаган» кебек лозунглар белән тормышка ашыра башладылар.

**Кызлар, намусыгызны яшьтән саклагыз. Алтын әйбер тагып кичен урамнарда йөрмәгез, сездән аны барыбер алачаклар.**

Кичен урамнан барганда көтмәгәндә бу әтрәк-әләмнәр йөгереп чыга һәм «секс» өчен куаклар арасына сөйри. Аннары артыңа әйләнеп карамыйча йөгерәсең, ә узып баручылар берни дә күрмәмешкә салышалар.

**Ни өчен сез әтиләр, әниләр, әбиләр һәм бабайлар, апалар һәм абыйлар шулай эшлисез?**

**Әйтеп бирәм: сез шул куркаклар, үзегезне үтерүдән яки милициягә кат-кат йөрүдән шүрлисез...**

**СВЕТА.**

Камыш бухтасы.
(«Щит и меч» газетасыннан алынды).

